Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының
Җәлил шәһәр тибындагы поселогы Советы

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

20.02.2015 ел № 148

**“Җәлил шәһәр тибындагы поселогы” муниципаль берәмлеге Советына депутатлар сайлау өчен бер мандатлы сайлау округлары схемасын раслау турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 12.06.2002 ел, № 67-ФЗ Федераль законның 18 статьясы, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 25 һәм 26 статьялары, «Җәлил шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Уставының 33 статьясы нигезендә, «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокуклары һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» бер мандатлы сайлау округлары схемасын карап, Сарман муниципаль районының Җәлил шәһәр тибындагы поселогы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Җәлил шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Советы депутатларын сайлауларны үткәрү өчен бер мандатлы сайлау округлары схемасын 1 нче кушымта нигезендә расларга.

2. Бер мандатлы сайлау округлары схемасын игълан итергэз, аның график рәсемен (кушымта 2) торак пункт территориясендә урнашкан мәгълүмат стендларында: Җәлил шәһәр тибындагы поселогы, Җиңүнең 30 еллыгы ур., 6 йорт адресы буенча урнаштырыга, Әхмәдиев ур., 20 һәм Сарман муниципаль районының «шәһәр тина Җәлил поселогы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны « Җәлил шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Советының оештыру эшләре бүлеге башлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Җәлил шәһәр тибындагы поселогы
Советы Рәисе И.Ф.Вафин